ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 419 от «05» 11 2025 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның 15 апрелендәге «Мамадыш
муниципаль районы «Мәгариф бүлеге»
педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация
төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм
мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча
дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма
комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУнең мәгълүмати-методик
бүлеге хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары
турындагы нигезләмәне раслау хакында»115 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы № под-1344/25 боерыгы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясының икенче өлеше нигезендә, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүнең тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. Внести Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 апрелендәге115 номерлы карары белән кабул ителгән Мамадыш муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУнең мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм

0000012984

өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 бүлектә нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» структурасындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә мөдире (башлыгы) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; структур бүлек мөдире (башлыгы) : муниципаль | | - | 24598,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | | | |
| | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | | | 24690,0 |

2. Әлеге карар үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М.Никифоров